РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ

Нижнеалькеевского сельского поселения

Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы

Түбән Әлки авыл җирлеге

СОВЕТЫ

Адрес: 422881, РТ, с. Нижнее Алькеево, ул. Советская, д. 55

Адресы: 422881, РТ, Түбән Әлки авылы, Совет ур., 55

тел.8 (84346) 77-2-15

факс: 8 (84346) 77-2-15


**РЕШЕНИЕ** Түбән Әлки авылы **КАРАР**

2025нче елның 30нчы гыйнвары 80 №

2018нче елның 14нче декабрендәге
"Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлегендә
Муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәне раслау турында"гы
Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлегенең
34нче номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

2023нче елның 12нче декабрендәге "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 594нче Федераль законының 12нче маддәсе,2024нче елның 8нче августындагы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 232нче номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.2018нче елның 14нче декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында"гы 34 нче номерлы( 2019нчы елның 20нче мартындагы 4нче номерлы карары, 2020нче елның 12нче февралендәге 4нче

номерлы карары, 2020нче елның 10нчы июнендәге 11нчы номерлы, 2021нче елның 30нчы июлендәге 28нче номерлы, 2023нче елның 9нчы февралендәге 28нче номерлы карары, 2023нче елның 7нче сентябрендәге 34нче карары, 2024нче елның 22нче мартындагы 55нче номерлы карары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә
4маддәнең4пунктында", муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына" сүзләрентөшереп калдырырга.;

6нчы маддәнең 4нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.";

13нче маддәне яңа редакциядә үзгәртергә:

"13нче маддә.Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындабелешмәләртапшыру»;

13нче маддәнең 7нче пунктында "(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре)" сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 8нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 10нчы пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрентөшереп калдырырга.

13нче маддәнең 11нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрентөшереп калдырырга.;

14нче маддәнең 3нче пунктындагы 5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «5) белем һәм квалификация турында документ;»

30нчы маддәнең 2нче пунктындагы 2.5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5.муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны узу чорында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыра һәм үткәрә;»

30нчы маддәнең 2нче пунктында түбәндәгеэчтәлекле2.5.1 пунктчаөстәргә.:

«2.5.1.дәүләт сере булып торган белешмәләргә билгеләнгән рәвешнекертүнерәсмиләштерә;»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлегенең мәгълүмат тактасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль район
Түбән Әлки авыл җирлеге
Советы Рәисе урынбасары

Ф.Ф.Мисалов